**Туган көнең-юбилееӊ белән сине, яраткан журналыбыз!!!**

32 нче урта гомуми белем биру мәктәбендә“Мәйдан”журналының 15 еллыгына багышлап төрле чаралар үткәрелде. Мәктәп, сыйныф стендларында журналының туган көненә багышланган мәгълүматлар урнаштырылды, татар теле кабинетларында күргәзмәләр оештырылды. Башлангыч сыйныф укучылары”Мәйданчык”тагы шигырьләрне укып, фикерләр алыштылар, шигырь эчтәлекләренә рәсемнәр ясадылар.

Соңгы вакыт эчендә “Мәйданчык” кушымтасында бер-бер артлы хикәя-шигырьләре басылган 4В сыйныф укучылары Богданова Азалия һәм Котдусова Ралина яшьтәшләренә үзләренең шигырь, хикәя, әкиятләрен укыдылар.

5Б сыйныфында “Мәйдан” журналының балалар өчен нәшер ителгән “Мәйданчык”кушымтасы белән таныштыру дәресе үткәрелде, укуылар танылган язучыларның һәм кечкенә авторларның әсәрләре белән таныштылар.

5А сыйныфында”Мәйдан” журналында чыгып килүче “Мәйданчык” кушымтасында басылган шигырьләрне уку кичәсе узды. Әлеге кичә укучыларны журнал белән тагын да якыннанрак таныштыру, аларны иҗатка тарту, шигъриятькә мәхәббәт уяту максатыннан үткәрелде.Укучылар бик теләп шигырьләр укыдылар, кайбер әсәрләрне такта янына чыгып рольләп укыдылар, сәхнәләштереп күрсәттеләр. Балаларның буш вакытларын файдалы һәм нәтиҗәле оештыруның бер юлы бу- матур әдәбиятка якын булу, газета- журналлар белән һәрдаим танышып тору. Әлеге кичәдән укучылар шундый фикерләр белән таралыштылар.

5В,Гсыйныфы укучылары татар әдәбияты дәресендә “Мәйдан” журналы сайтына күзәтү ясадылар. Журналның эчтәлеге һәм анда бастырылган материаллар белән таныштылар.

7,8нче сыйныф укучылары Мәйдан” журналының 15 еллыгына багышланган стенгазета чыгардылар.

Яраткан журналыбызның туган көненә багышлап уздырылган чараларда барлык татар теле укытучылары да актив катнашты.









